СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**11.04.2016**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 77**

Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Зеленодольск муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында

2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында», 2012 елның 03 декабрендәге 230-ФЗ номерлы «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» Федераль законнары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Зеленодольск муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе турындагы Нигезләмәне расларга (кушымта бирелә).

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**

Зеленодольск муниципаль районы
Советы
2016 елның 11 апрелендәге
77 номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Зеленодольск муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе турындагы**
**нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә белән Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, аларның ирләренең (хатыннарының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны (алга таба - керемнәр, чыгымнар, милек һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр) Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба - рәсми сайт) урнаштыру, шулай ук әлеге белешмәләрне гомумроссия, республика һәм муниципаль массакүләм мәгълүмат чараларына (алга таба - массакүләм мәгълүмат чаралары) аларның мөрәҗәгатьләренә бәйле рәвештә бастырып чыгару өчен бирү тәртибе билгеләнә.

2. Рәсми сайтта урнаштырыла һәм массакүләм мәгълүмат чараларына керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында түбәндәге мәгълүматларны бастырып чыгару өчен бирелә:

а) Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфа биләүче затка караган (алга таба - муниципаль вазыйфа биләүче зат), аның хатынына (иренә) һәм балигъ булмаган балаларга милек хокукында яисә алар файдалана торган һәр объектның төре, мәйданы һәм урыны күрсәтелгән күчемсез мөлкәт объектлары исемлеге;

б) муниципаль вазыйфаны биләүче затка, аның хатынына (иренә) һәм балигъ булмаган балаларына милек хокукында булган, төре, маркасы күрсәтелгән транспорт чаралары исемлеге;

в) муниципаль вазыйфа биләүче затның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының декларацияләнгән еллык кереме;

г) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу

өлешләре, пайлар) сатып алу, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы хисап чорына кадәрге соңгы өч елда муниципаль вазыйфаны биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып киткән очракта, алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары турындагы белешмәләр.

3. Рәсми сайтта урнаштырыла торган һәм массакүләм мәгълүмат чараларына керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне бастырып чыгару өчен түбәндәгеләрне күрсәтү тыела:

а) муниципаль вазыйфаны биләүче затның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, атап үтелгән затларның милек хокукында булган мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында башка мәгълүматлар (әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән белешмәләрдән тыш);

б) муниципаль вазыйфаны биләүче затның хатынының (иренең), балаларының һәм башка гаилә әгъзаларының шәхси мәгълүматлары;

в) муниципаль вазыйфаны биләүче затның, аның хатынының (иренең), балаларының һәм гаиләнең башка әгъзаларының яшәү урынын, почта адресын, телефонын һәм башка индивидуаль коммуникация чараларын билгеләргә мөмкинлек бирә торган белешмәләр;

г) муниципаль вазыйфаны биләүче затка, аның хатынына (иренә), балаларга, гаиләнең башка әгъзаларына милек хокукында яисә алар файдалануында булган күчемсез мөлкәт объектларының урнашу урынын билгеләргә мөмкинлек бирә торган мәгълүматларлар;

д) дәүләт серенә кертелгән яки конфиденциаль булып торучы мәгълүмат.

4. Әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләр рәсми сайтта муниципаль вазыйфаны биләүче затның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү өчен билгеләнгән вакыт тәмамланган көннән алып 14 эш көне эчендә урнаштырыла.

5. Әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән, муниципаль вазыйфаны биләүче зат тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында рәсми сайтка Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы (Зеленодольск муниципаль районы Советы рәисе) вәкаләтле кадрлар хезмәте (кадрлар эше буенча белгеч) тарафыннан тәэмин ителә (алга таба - кадрлар хезмәте).

6. Кадрлар хезмәте:

а) массакүләм мәгълүмат чараларыннан сорау алынган көннән алып 3 көн эчендә аның турында гарызнамә кергән муниципаль вазыйфаны биләүче затка хәбәр итә;

б) массакүләм мәгълүмат чараларыннан сорау алынган көннән соң, әгәр соралган белешмәләр рәсми сайтта булмаса, 7 көн эчендә аңа әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне бирүне тәэмин итә.

7. Кадрлар хезмәтендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләр Россия Федерациясе законнары нигезендә әлеге Нигезләмәне үтәмәгән өчен, шулай ук дәүләт серенә кертелгән яки конфиденциаль булган белешмәләрне игълан иткән өчен җаваплы.